ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.10.2025 г.Мензелинск № 350

**Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 23.11.2012 ел «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Минзәлә муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» № 1347 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 6 сентябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә хезмәт хакы бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге №477 карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты №669 карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Хезмәт хакы бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Минзәлә муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 23.11.2012 ел №1347 карарына (Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 24.10.2013 ел №1071, 19.03.2014 ел №265, 12.12.2014 ел №1264, 23.11.2015 ел №816, 14.07.2016 ел №776, 24.08.2017 ел №807, 02.02.2018 ел №98, 18.02.2022 ел №49, 23.12.2022 ел №431, 19.06.2024 ел №195, 21.10.2024 ел №323, 23.05.2025 ел №175 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (беркетелгән).

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе Л. И. Кондратьевага йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Кәримов

Татарстан Республикасы Минзәлә
муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына 1 нче кушымта
23.11.2012 ел № 1347
(Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль
районы Башкарма комитетының
21.10.2025 №350 карары редакциясендә)

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТЫННАН ФИНАНСЛАНА ТОРГАН БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕНЕҢ ТАРИФ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИФ СТАВКАЛАРЫ (ОКЛАДЛАРЫ)

| Бердәм тариф челтәрен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (хезмәт хакы), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 25 650 |
| 2 | 1,0113 | 25 940 |
| 3 | 1,0234 | 26 250 |
| 4 | 1,0347 | 26 540 |
| 5 | 1,0476 | 26 871 |
| 6 | 1,0596 | 27 180 |
| 7 | 1,0729 | 27 520 |
| 8 | 1,0858 | 27 851 |
| 9 | 1,0982 | 28 170 |
| 10 | 1,1119 | 28 520 |
| 11 | 1,1251 | 28 860 |
| 12 | 1,1392 | 29 220 |
| 13 | 1,1536 | 29 590 |
| 14 | 1,1676 | 29 950 |
| 15 | 1,1825 | 30 331 |
| 16 | 1,1973 | 30 711 |
| 17 | 1,2125 | 31 100 |
| 18 | 1,2281 | 31 501 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1- 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.